ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исемендәге
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**А. Ә. Тимерханов,**
**С. Ф. Гарифуллин**

# ТАТАРЧА-РУСЧА-ИНГЛИЗЧӘ МӘКТӘП СҮЗЛЕГЕ

12 000 чамасы сүз һәм сүзтезмә,
1000 ләп фразеологик берәмлекне эченә ала

КАЗАН

«МӘГАРИФ – ВАКЫТ» НӘШРИЯТЫ

2014

АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА
им. Г. ИБРАГИМОВА

**А. А. Тимерханов,**
**С. Ф. Гарифуллин**

# ТАТАРСКО-РУССКО-АНГЛИЙСКИЙ ШКОЛЬНЫЙ СЛОВАРЬ

Около 12 000 слов и словосочетаний,
1000 фразеологических единиц

КАЗАНЬ

ИЗДАТЕЛЬСТВО «МАГАРИФ – ВАКЫТ»

2014

TATARSTAN ACADEMY OF SCIENCES
G. IBRAGIMOV INSTITUTE
FOR LANGUAGE, LITERATURE AND ART

**A. A. Timerkhanov,**
**S. F. Garifullin**

# TATAR-RUSSIAN-ENGLISH SCHOOL DICTIONARY

About 12 000 words and phrases,
1000 phraseological units

KAZAN

PUBLISHING HOUSE «MAGARIF – VAKYT»

2014

УДК 811.512.145:811.161.1:811.111´374
ББК 81.2Тат:81.2Рус:81.2Англ-4
Т 41

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының
Гыйльми советы карары нигезендә басыла

*Россия Федерациясенең «Авторлык хокуклары һәм арадаш хокуклар турында»гы Законы белән саклана. Китапка кергән материалларны тулысы белән яки өлешчә башка басмалар өчен файдалану, төрле электрон мәгълүмат чыганакларына күчереп яки төшереп алу авторлык хокукына ия булган затның язма рөхсәтеннән башка катгый тыела.*

**Фәнни редакторы**

филология фәннәре докторы, доцент,
ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИның лексикография бүлеге мөдире
*А. Ә. Тимерханов*

**Рецензентлар:**

филология фәннәре докторы, Россия гадел хөкем академиясенең
Казан филиалы профессоры *М. Б. Хәйруллин;*
филология фәннәре кандидаты, Казан федераль университетының
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты профессоры
*Р. Г. Мөхәммәтдинова*

**Тимерханов А. Ә.**

**Т 41** Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге / төз.: А. Ә. Тимерханов, С. Ф. Гарифуллин; фәнни ред., кереш мәкалә, кушымта авторы А. Ә. Тимерханов. – Казан: Мәгариф – Вакыт, 2014. – 512 б.
ISBN 978-5-905943-30-0

Сүзлек мәктәптә татар һәм рус, шулай ук инглиз телләрен үзләштерүдә гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә. Сүзлеккә барлыгы 12 000 чамасы сүз, сүзтезмә һәм 1000 ләп тотрыклы гыйбарә кертелде. Ул татар әдәби теленең киң кулланышта йөргән актуаль лексикасын һәм фразеологиясен эченә ала.

Сүзлек, укытучылар һәм мәктәп укучылары белән беррәттән, студентлар, журналистлар, гомумән киң катлау укучылар өчен дә кызыклы, шул ук вакытта файдалы да чыганак була ала.

**ISBN 978-5-905943-30-0**

© ТФА Г. Ибраһимов исем. ТӘһСИ, 2014
© Тимерханов А. Ә., Гарифуллин С. Ф., 2014

## СҮЗ БАШЫ

Үткән гасырның 90 нчы еллары илебез тормышында зур үзгәртеп корулар белән истә калды. Җитди үзгәрешләр, илнең дәүләт төзелеше, социаль-сәяси системасы һәм иктисади үсеш курсы белән генә чикләнмичә, миллионлаган кешенең рухи тормышында, үзаңында һәм дөньяга карашында да киң чагылыш тапты. Бүгенге күпмилләтле Россия составында яшәүче халыклар үзләренең асылына кайтырга, яңа урнашкан чынбарлык күзлегеннән карап, үзләренең тарихи үсеш юлларын ачыкларга һәм киләчәккә кыйбласын билгеләргә мөмкинлек алдылар. «Үзгәртеп кору җиле» тәэсирендә телне, милли-мәдәни традицияләрне тергезү, өйрәнү һәм үстерү мәсьәләләре күп кенә милли республикаларда алып барылган эшчәнлекнең төп юнәлешләреннән берсен тәшкил итте.

Татарстанда, беренчеләрдән булып, татар халкы һәм биредә яшәүче башка халыкларның бай милли-мәдәни мирасын саклап калу, өйрәнү һәм үстерүгә юнәлтелгән максатчан чаралар гамәлгә ашырыла башлады. Бу шартларда милли мәдәниятне тергезү һәм татар халкының милли үзенчәлеген ныгытуда татар теле төп нигезгә әверелде.

Республикада дәүләт югарылыгында милли мәсьәләләр һәм тел өлкәсендә яңа үсеш концепциясен кабул итү, аны актив рәвештә тормышка ашыру татар телен саклап калу, өйрәнү һәм үстерү өчен уңай шартлар тудыруга китерде. Республика күләмендә иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни тормышта телебезнең роле һәм әһәмияте артты, куллану чикләре киңәйде. 1992 елда «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында»гы законны кабул итү бу юнәлештәге иң зур һәм җитди адым булды. Анда татар теле рәсми рәвештә дәүләт теле статусындагы тел буларак теркәлде. Һәм хәзерге чорда татар телен үстерү өчен яңа көчле этәргеч булдырылды. Туган телнең абруе артты, аның кулланылыш даирәсе шактый киңәйде.

Бүген татар теле мәктәпкәчә учреждениеләр, урта белем бирү системасы һәм югары уку йортларында

өйрәтелә. Ләкин региональ компонент кысаларында милли телләрне укытуны кыскарту яки бердәм дәүләт имтиханын бары тик рус телендә генә тапшыру шартын кертү татар теле һәм башка милли телләрнең мәгариф системасында укытылу күләмен, аларның кулланылышын кискен рәвештә киметүгә китерергә мөмкин.

Шулай да, бүген татарча китаплар бастыру эшчәнлеге активлаша бара, милли радио һәм телевидениенең татарча эшләвенә бәйле уңай күренешләр күзәтелә. Театр һәм концерт, күргәзмә залларында, яшьләр өчен күңел ачу үзәкләрендә һәм күпсанлы халык катнаша торган башка чараларда да татар теле ешрак яңгырый башлады.

Татар теленең дәүләт идарәсе органнары эшчәнлегендә активрак кулланыла башлавын да әһәмиятле уңай күренеш буларак кабул итәргә кирәк. Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актларының даими рәвештә татарча текстлары басыла тора. Суд эшчәнлеген, рәсми эш кәгазьләрен тутыру һәм теркәүне татар телендә дә алып бару омтылышы күзәтелә. Төрле кыенлыклар булуга карамастан, бу юнәлештәге чаралар татар теленең рәсми аралашу өлкәсендә кулланылыш күләмен киңәйтүгә, аның сыйфатына сизелерлек уңай йогынты ясыйлар.

Шуның белән бергә, татар телен һәм, гомумән, гаять бай әдәби, мәдәни мирасыбызны фәнни нигездә өйрәнү чикләре дә киңәя бара. Өчтомлык «Хәзерге татар теленең академик грамматикасы» (1992–1993) төзелүе, татар фольклорының татар һәм рус телләрендә күләмле җыентыклары, Г. Исхакый, Г. Тукай, Г. Ибраһимов, М. Җәлил һ. б. классик язучыларыбыз әсәрләренең күптомлыклары нәшер ителә башлавы, милли фәнебезнең башка юнәлешләрендә бүгенге үсеш таләпләренә җавап бирердәй фундаменталь хезмәтләр әзерләнүе – татар фәне тарихында зур алга китеш булуны раслый.

Соңгы елларда төрле эчтәлектәге татарча сүзлекләр эшләп бастыруга да зур игътибар ителә башлады. Әлеге юнәлешне үстерү хәзерге чорда аеруча әһәмияткә ия, чөнки сәяси-иҗтимагый тормыш, икътисад, мәдәният өлкәләрендәге интенсив процесслар тәэсирендә телгә, аеруча аның иң сизгер өлеше – лексик системасына әледән-әле өстәлеп торган күптөрле сүзләрне, терминнарны теркәү ихтыяҗы үзен ныграк сиздерә килә. Мондый вазгыять татар лексикографиясе, гомумән, татар тел белеменең актив рәвештә нәтиҗәле үсешенә этәргеч бирә.

Татар лексикографиясенең күптәннән килә торган бай традицияләре бар. Аларның нигезен, иң элек, төрле максатларда төзелгән икетелле, башлыча русча-татарча һәм татарча-русча, сүзлекләр тәшкил итә. Бу табигый да, чөнки күп гасырлар

дәвамында үзара аралашып яшәү нәтиҗәсендә татар һәм рус халыклары арасында тыгыз социаль-икътисади, мәдәни бәйләнешләр урнаша, соңыннан элеккеге СССР һәм хәзерге Россия халыкларының уртак казанышына әйләнгән рухи-мәдәни киңлек барлыкка килә. Электән үк шундый үзара тыгыз бәйләнештә яшәү тәрҗемә сүзлекләр һәм төрле эчтәлектәге сөйләшмәлекләр төзеп чыгаруга этәрә. Еш кына андый басмалар татарча текстларны рус теленә һәм киресенчә тәрҗемә итүдә төп белешмә әсбап булып хезмәт итә.

Берничә гасыр дәвамында сүзлекләр төзүдә тупланган зур тәҗрибә алга таба лексикография өлкәсендә тагын да күләмлерәк проектларны гамәлгә ашыруда төпле нигез була. Совет чоры һәм аннан соңгы чор төрки-татар лексикографиясенең иң күркәм традицияләре өчтомлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (Казан, 1977–1981), «Русча-татарча сүзлек» (Мәскәү, 1984), икетомлы «Татарча-русча сүзлек» (Казан, 2007) һәм башка шундый фундаменталь басмаларда чагылыш тапты. Хәзерге татар лексикографиясенең яңа зур уңышларының берсе – бертомлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» басылып чыгу (Казан, 2005). Сүзлекне профессор Ф. Ә. Ганиевнең фәнни җитәкчелегендә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләүче бер төркем лексикограф галимнәр төзеде. Ул озак еллар дәвамында күп көч, тырышлык куеп башкарылган зур эш нәтиҗәсе. Хезмәт әлеге төр сүзлекләрне төзүдәге барлык алдынгы уңай тәҗрибәне исәпкә алып эшләнгән. Сүзлеккә 58 мең сүз һәм фразеологик берәмлек кертелгән. Ул татар халкының рухи-мәдәни мирасын һәм мәгълүм күләмдә бөтен төрки дөньяның милли-тел тасвирланышын чагылдырган гаять бай чыганак булып хезмәт итә.

Бүген татар теленең биш-алты томнан торачак яңа, тагын да тулырак һәм камилрәк аңлатмалы сүзлеген төзү юнәлешендә актив эш алып барыла. Аның беренче ике томы инде төзелеп беткән, калганнары эшләнә тора. Әлеге хезмәттә телебезнең байлыгы тагын да тулырак чагылыш табачак.

Төрле чорларда татар телен чит телләргә бәйләп, икетелле, сирәгрәк булса да, өчтелле сүзлекләр дә төзелгән. Аларны эшләүдә инглиз, гарәп, фарсы, төрек һ. б. телләр файдаланылган. Дөрес, андый сүзлекләр саны күпкә азрак булган. Мисал өчен, төрле елларга караган унбишләп гарәпчә-татарча һәм татарча-гарәпчә сүзлек булуы мәгълүм. Бу нисбәттән Г. Ишмөхәммәтовның зур булмаган күптелле «Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә»сен (Казан, 1954) телгә алырга мөмкин.

Татар һәм башка телләр материалы нигезендә төзелгән күләмлерәк лексикографик басмаларның чыгуы

XX йөзнең икенче яртысына һәм хәзерге чорга карый. Андый хезмәтләр арасыннан, һичшиксез, 1965 елда дөнья күргән (Казан, 854 б.) һәм 1993 елда (Казан, 448 б.) кабат басылып чыккан «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»н күрсәтергә кирәк. Сүзлектә милли мәдәниятне гомумсоветлаштыру чорында өлешчә пассивлашкан яки кулланыштан бөтенләй төшеп калган кабатланмас бай лексика тупланган. Татар һәм рус телләренә тәрҗемә итеп бирелгән гарәп теле материалы, сүзләргә китерелгән аңлатмалар, гарәп теленнән кушымта рәвешендә бирелгән кыскача грамматик белешмә – барысы бергә бу хезмәтне тел белгечләре һәм киң катлау укучылар өчен чын мәгънәсендә кыйммәтле һәм бердән-бер кулланма чыганак итә.

Соңгы елларда татар һәм гарәп телләре нигезендә төзелгән зур булмаган яңа терминологик сүзлекләр дә басылды. Мисал итеп, «Мөселман терминологиясе сүзлеге»н (Казан, 2006) китерергә мөмкин. Милли мәдәниятне һәм аның мөһим бер тармагы буларак динне тергезү, үстерү шартларында чыгышы белән нигездә гарәп теленә караган мөселман терминологиясенең бер өлеше кабат актуальләшә һәм актив рәвештә хәзерге татар теленең лексик составында үзенең төпле урынын биләргә омтыла. Калган зур өлешен исә эшкәртеп, сүзлекләргә кертү сорала. Мондый төр сүзлекләр аерым бер өлкәгә караган ихтыяҗларны канәгатьләндерү максаты белән төзелә. Шунлыктан алар тел материалын тулы чагылдыруга йөз тотмыйлар. Шулай да хәзерге татар лексикографиясенең үсешендә аерым тармак терминологиясе сүзлекләрен төзү мөһим бер юнәлешне тәшкил итә.

Татар теленә бәйле икетелле сүзлекләрдән татар һәм төрек галимнәренең уртак тырышлыгы белән төзелгән шактый күләмле «Татарча-төрекчә сүзлек» (Казан–Мәскәү, 1997) һәм «Төрекчә-татарча сүзлек» (Казан–Мәскәү, 1998) тә игътибарга лаек. Аларда тупланган бай материал уртак тарихи тамырларыбызны һәм Татарстан белән Төркия арасындагы социаль-икътисади, мәдәни һ. б. өлкәләргә караган бүгенге хезмәттәшлекнең югары үсеш дәрәҗәсен чагылдыра.

Татарстан Республикасының башка дәүләтләр белән төрле юнәлештә халыкара хезмәттәшлек җәелдерә баруы аралашуга карата да яңа таләпләр куя. Мондый вазгыять татар телен чит телләргә бәйләп, икетелле һәм күптелле зуррак сүзлекләр эшләп чыгару ихтыяҗын тудыра. Глобальләшү һәм халыкара багланышларның аеруча тиз үсеш алуы шартларында мөстәкыйль дәүләтләр югарылыгында да, Россиянең аерым төбәкләре дәрәҗәсендә дә тормыш һәм яшәешнең төрле өлкәләрендә белгечләр арасында тәҗрибә уртаклашу арта бара. Галимнәр, мәдәният хезмәткәрләре, бизнес вәкилләре, спортчыларның халыкара конгресслар һәм симпо-

зиумнарда, сәяси һәм икътисади чараларда, төрле спорт ярышларында катнашуы киңрәк төс ала, чит ил компанияләре белән хезмәттәшлек итү өчен яңа мөмкинлекләр ачыла. Күпчелек очракта мондый бәйләнешләрдә төп аралашу чарасы булып инглиз теле хезмәт итә. Галимнәр фикеренә караганда, бүген Җир шарында миллиард ярымнан артык кеше аралашу һәм мәгълүмат алмашу максатында нәкъ менә шушы телдән файдалана. Сәясәт, икътисад өлкәсендә күзәтелә торган глобаль процесслар, югары технологияләрнең гаять тиз үсеш алуы, Интернет челтәренең актив, ә, бәлки, хәтта агрессив рәвештә кулланылыш даирәсе киңәюе – барысы да, ул телдә сөйләшүче илләрдән саналган Бөекбритания, АКШ, Канада, Австралия һ. б. лар белән генә чикләнмичә, инглиз теленең таралыш мәйданын күпкә арттыра. Шул рәвешле, инглиз теле глобаль аралашу чарасына әйләнеп бара. Киләчәккә йөз тотып эш иткәндә, инглиз телен белү заманча карашлы кешенең профессиональ эшчәнлегенә дә сизелерлек йогынты ясарлык, алыштыргысыз гамәли бер сыйфат булып торачак. Шушы үсеш юнәлешләрен исәпкә алып, халыкара лексикография өлкәсендә милли (татар) һәм чит (инглиз) телләр нигезендә сүзлекләр эшләүгә күбрәк игътибар итәлә башлады. Башка чаралар белән берррәттән, андый алым, халыкның лингвоэтник үзенчәлекләрен саклаган хәлдә, төрле мәдәният вәкилләренә гомумдөнья күләмендәге лингвистик процесслар агымына кушылу мөмкинлеге бирә. Моннан тыш, телара элемтәләр милли тел системасын баету һәм үстерү өчен генә түгел, ә бәлки шул телләрдә сөйләшүчеләргә бер-берсенең мәдәниятләрен дөрес һәм тулы аңлау өчен дә уңай бер нигез булып тора.

Шул ук вакытта, классик һәм хәзерге татар әдәбияты үрнәкләрен дөньякүләм укучыга җиткерү максатында, татар язучыларының әсәрләрен инглиз теленә һәм киң таралган башка телләргә дә тәрҗемә итү кирәклеге торган саен үзен ачыграк сиздерә бара. Бу өлкәдә лексикографик эшчәнлек төп юнәлешләрнең берсен тәшкил итә. Шунлыктан, татар һәм инглиз телләре материалы нигезендә икетелле сүзлекләр булдыруның әһәмияте бүген тагын да арта төшә.

Хәзерге вакытта мәктәпләр, югары уку йортлары өчен төзелгән икетелле, күптелле сүзлекләр бар. Күләме ягыннан артык зур булмаган андый сүзлекләр арасында түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин: «Татарча-немецча сүзлек» (Казан, 1989), «Инглизчә-русча-татарча физика терминнары сүзлеге» (Казан, 1996), «Инглизчә-татарча-русча гомумтөзелеш лексикасы сүзлеге» (Казан, 1996), «Немецча-татарча-русча гомумтөзелеш лексикасы сүзлеге» (Казан, 1996), «Инглизчә-татарча-русча уку-укыту минимумы сүзлеге» (Казан, 1999); «Информатика һәм мәгълүмат технологияләре

терминнары: Инглизчә-татарча-русча аңлатмалы сүзлек» (Казан, 2006) һ. б. Төрле төрки республикаларда һәм чит илләрдә нәшер ителгән инглиз теленә бәйле башка икетелле сүзлекләр дә бар (Tatar-English/English-Tatar Dictionary, 1994, 200 p.). Алар арасында төрекчә-инглизчә һәм инглизчә-төрекчә сүзлекләр тел материалын тулырак чагылдыруы белән аерылып торалар.

Татарча-русча икетеллелек шартларында инглиз теленә өйрәтү, башлыча, рус теле аша алып барылганлыктан, мондый төр уку-укыту сүзлекләрен арадашчы тел саналган рус теленнән башка төзү күпчелек укучылар өчен алардан файдалануда аерым кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин. Гәрчә, шунысын да искәртергә кирәк: соңгы дистә елда чит телләргә өйрәткәндә, туган телгә, татар теленә таянып укыту юнәлеше дә үсеш алып килә. Өчтелле сүзлекләр нигезендә эшләнгән икетелле сүзлекләр тулырак һәм төгәлрәк булып чыга. Шуларны исәпкә алып, киләчәктә күләмлерәк татарча-инглизчә һәм инглизчә-татарча сүзлекләр төзү юнәлешендә беренче тәҗрибә буларак, әлеге өчтелле «Татарча-русча-инглизчә мәктәп сүзлеге»н тәкъдим итәбез. Сүзлекне төзүче авторлар – Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының элеккеге хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты С. Ф. Гарифуллин һәм шул ук институтның лексикография бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы А. Ә. Тимерханов. Сүзлек укучыга яхшы таныш булган «Татарча-русча уку-укыту сүзлеге»нең (Мәскәү, 1993, 416 б.) сүзлекчәсе һәм аның төп лексикографик принципларына таянып төзелде. Сүзлекнең максаты – татар сүзләренең рус һәм инглиз телләрендә мөмкин кадәр дөрес һәм төгәл тәрҗемәсен бирү. Сүзлеккә 12 меңгә якын сүз һәм сүзтезмә кертелде, шул исәптән 1000 ләп актуаль булган фразеологик берәмлек һәм аларның рус, инглиз телләрендә төгәл тәңгәлләре, ә андыйлар булмаган очракта – тасвирлама вариантлары бирелде. Сүзлектә татар теленең хәзерге чордагы үсешенә хас үзенчәлекләр, аның лексик составында яңа барлыкка килгән яисә башка телләрдән кереп үзләштерелгән берәмлекләр дә теркәлде. Бу исә сүзлекнең татарча лөгатьлеген берникадәр яңартуга китерде.

Татар фигыленең төп формасы итеп *-ырга*/*-ергә* инфинитив формасы алынды. Ул үзенең функциональ-семантик күрсәткечләре белән рус телендәге фигыльнең башлангыч формасына туры килә. Күп кенә фигыльләр, бигрәк тә тезмә төренә караганнары, инглиз телендә тегге яки бу фигыль белән бәйләнештә аерым бер мәгънәне белдергәндә генә кулланыла торган бәйлекләр белән бирелде. Шулай ук, бер сүз төркеменә караган сүзләрнең икенче бер төркемгә караган сүзләр функциясендә килүе исәпкә алын-

ды. Инглиз теленең америка сөйләшенә хас берәмлекләре һәм стилистик төсмере белән аерылып торган сүзләр махсус билгеләр белән күрсәтелде.

Сүзлеккә теркәп, инглиз теле грамматикасы турында кыскача белешмә бирелә. Әлеге материал тел кагыйдәләрен аңларга, аларны үзләштерергә ярдәм итәр һәм туган тел аша чит телне өйрәнү процессын җиңеләйтер дип ышанабыз.

Сүзлек киң катлау укучыларга – татар һәм рус телләреннән үзләренең сүз запасын арттырырга һәм белемнәрен камилләштерергә теләүчеләргә, шулай ук, дөньякүләм аралашу чарасы статусын дәгъва иткән инглиз телен үзләштерергә омтылучы барлык затларга тәкъдим ителә. Әлеге хезмәт мәктәп укытучылары, студентлар, аспирантлар һәм югары уку йортлары мөгаллим-мөгаллимәләре өчен генә түгел, инглиз телен туган тел (татар, рус телләре) аша өйрәнүче яки һөнәри эшчәнлегенә бәйле рәвештә чит телдән файдаланучыларның да һәркайсына гамәли кулланма була ала. Сүзлекнең тәрҗемә итүдә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары эшендә дә файдалы чыганак ролен үтәячәгенә шик юк.

Сүзлекнең эчтәлегенә карата әйтеләчәк фикер һәм искәрмәләр өчен авторлар алдан ук рәхмәтләрен белдерәләр. Бәяләмәләрне түбәндәге адреска җибәрә аласыз: 420111, Казан шәһ., Лобачевский ур., 2/31, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, лексикография бүлеге, 48 бүлмә. Электрон почта адресы: iyali.anrt@mail.ru

*А. Ә. Тимерханов*

## ПРЕДИСЛОВИЕ

90-е годы прошлого столетия были отмечены крупными преобразованиями в жизни всей страны. Серьёзные перемены коснулись не только государственного устройства, социально-политической системы и экономического курса развития страны, но нашли отражение и в духовной жизни, сознании и мировоззрении миллионов людей. В условиях современной многонациональной России народы, проживающие на её территории, вновь получили возможность обратиться к своим истокам, переосмыслить свой исторический путь с позиции новой складывающейся действительности и наметить ориентиры на будущее. Свежий «ветер перемен» способствовал тому, что возрождение и развитие национально-культурных ценностей и языковых традиций стали одним из приоритетных направлений деятельности многих национальных республик России.

В Татарстане, в одном из первых среди национальных республик, были разработаны и реализованы целенаправленные меры по сохранению и развитию богатого национально-культурного наследия татарского и других народов, проживающих в республике. В этих условиях татарский язык естественным образом стал основой возрождения национальной культуры и укрепления национальной идентичности татарского народа.

Принятие на государственном уровне новой концепции национально-языкового развития в республике и её активная реализация способствовали созданию благоприятных условий для сохранения, изучения и развития татарского языка, заметному повышению его роли в общественно-политической и культурной жизни республики, расширению возможностей его применения. Самым серьёзным и значительным шагом в этом направлении стало принятие в 1992 году закона «О языках народов Республики Татарстан», который наделил татарский язык высоким статусом государственного языка. Таким образом, на современном этапе татарский

язык получил новый мощный импульс развития. Повысился престиж родного языка, заметно расширилась сфера его использования.

Сегодня татарский язык изучается в системе дошкольного и школьного образования, выделяются программные часы на преподавание татарского языка в высших учебных заведениях. Однако последние законодательные инициативы в стране, направленные на сокращение преподавания национальных языков в рамках изучения дисциплин регионального компонента или их исключения из школьных и вузовских программ, а также введение сдачи единого государственного экзамена исключительно на русском языке могут существенно повлиять на объём изучения татарского языка и других национальных языков в системе образования и, как следствие, на сферу их использования.

Тем не менее сегодня активно развивается издательская деятельность на татарском языке, наметились позитивные сдвиги в вещании на татарском языке на национальном радио и телевидении. Татарский язык всё чаще стал звучать в театрах и концертных залах, на выставках, в молодёжных культурно-развлекательных центрах и на других массовых мероприятиях.

Важным положительным моментом является всё более активное использование татарского языка в деятельности государственных органов управления. На постоянной основе издаются татарские тексты всех законодательных и других нормативно-правовых актов Российской Федерации, Республики Татарстан, делаются попытки организации судопроизводственной деятельности, ведения делопроизводства на татарском языке. Несмотря на имеющиеся трудности разного характера, предпринимаемые усилия оказывают заметное положительное влияние на объём и качество применения татарского языка в официально-деловой сфере коммуникации.

Вместе с тем расширяются границы научного изучения татарского языка и богатейшего литературного, культурного наследия. Выход в свет академической «Татарской грамматики» в трёх томах (1992–1993), объёмного свода татарского фольклора, издание многотомных собраний произведений Г. Исхаки, Г. Тукая, Г. Ибрагимова, М. Джалиля и других фундаментальных трудов, отвечающих современным требованиям исследования, знаменуют собой огромный прорыв в истории развития всей татарской научной мысли.

В последние годы всё больше внимания стало уделяться составлению и изданию татарских словарей различных типов. Развитие данного направления приобретает в нынешний период особую актуальность, так как всё больше возникает потребность в фиксации

многочисленных изменений в языке (прежде всего в наиболее проницаемой его части – лексической системе), обусловленных бурными процессами в общественно-политической, экономической, культурной жизни в стране и мире. Эти условия способствуют в целом динамичному и плодотворному развитию татарской лексикографии и всего татарского языкознания.

Татарская лексикография имеет давние и богатые традиции, которые во многом основаны на опыте составления двуязычных словарей, преследовавших разные цели. Это были главным образом русско-татарские и татарско-русские словари, что вполне естественно, так как на протяжении многовекового соседства и сосуществования между татарским и русским народами сложились прочные социально-экономические и культурные связи, сформировалось общее духовно-культурное пространство, ставшее впоследствии достоянием всех народов бывшего СССР и современной России. Такое тесное взаимодействие с давних пор и вызвало необходимость в создании переводных словарей и разговорников разных типов. Нередко такие издания служили основным справочным пособием в процессе перевода татарских текстов на русский язык и наоборот.

В дальнейшем значительный положительный опыт в составлении этих и других словарей, накопленный на протяжении нескольких столетий, стал надёжной основой для разработки и успешной реализации более масштабных лексикографических проектов на современном этапе. Лучшие традиции тюрко-татарской лексикографии советского и постсоветского периодов нашли отражение в «Толковом словаре татарского языка» в 3-х томах (Казань, 1977–1981), «Русско-татарском словаре» (Москва, 1984), «Татарско-русском словаре» (Казань, 1998), «Татарско-русском словаре» в 2-х томах (Казань, 2007) и ряде других фундаментальных изданий. Очередным значительным достижением татарской лексикографии новейшего периода стал выход в свет однотомного «Толкового словаря татарского языка» (Казань, 2005), подготовленного коллективом учёных Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Татарстана под научным руководством проф. Ф. А. Ганиева. Это плод большой и долгой кропотливой работы на основе углубления и совершенствования научных принципов построения такого рода словарей, а также использования всего современного положительного опыта в данной области. В словарь вошло около 58 тысяч слов и фразеологических единиц. Он будет служить богатейшим источником, отражающим духовно-культурное наследие татарского народа и национально-языковую картину татарского, а в определённой степени и тюркского мира.

Продолжается интенсивная работа по созданию новой, ещё более полной и совершенной версии «Толкового словаря татарского языка» в 5–6-ти томах, первые два тома которого уже завершены, а остальные части находятся в разработке.

Наряду с этим в разные периоды создавались и другие двуязычные, реже многоязычные словари с привлечением английского, арабского, персидского, турецкого и других языков. Однако их было значительно меньше. Всего насчитывается около пятнадцати арабско-татарских и татарско-арабских словарей, относящихся к разным периодам. В связи с этим можно упомянуть небольшой многоязычный словарь Г. Ишмухамметова «Төрки, фарсы, гарәп һәм казахча, татарча, русча сүзлекчә» (Казань, 1954).

Выход наиболее объёмных изданий такого рода, составленных на основе татарского и других языков, относится ко второй половине XX в. и к новейшему периоду. Среди таких трудов, несомненно, следует выделить «Арабско-татарско-русский словарь заимствований», увидевший свет в 1965 г. (Казань, 854 с.) и переизданный в 1993 г. (Казань, 448 с.). Это своего рода хранилище той богатой и неповторимой лексики, часть которой отошла в пассивный словарь татарского языка или полностью вышла из оборота в процессе всеобщей советизации национальной культуры. Богатейший материал из арабского языка с переводом на татарский и русский языки, отдельные объяснения, приложение с кратким грамматическим очерком арабского языка делают этот труд поистине ценным для лингвистов и широкого круга читателей.

В последние годы издаются небольшие по объёму новые терминологические словари, составленные на материале татарского и арабского языков. В частности, увидел свет «Словарь мусульманской терминологии» (Казань, 2006). В условиях возрождения, развития национальной культуры и религии как важнейшей её составляющей часть мусульманской терминологии, в основе своей арабского происхождения, вновь актуализируется и всё активнее претендует занять свою нишу и утвердиться в современном татарском языке. А другая часть требует разработки и включения в лексикографические пособия. Поэтому составление таких словарей, хотя и преследующих узкоспециальные цели и не претендующих на полноту представленного языкового материала, является важным направлением развития современной татарской лексикографии.

Из двуязычных татарских словарей также достойны внимания довольно объёмные «Татарско-турецкий словарь» (Казань–Москва, 1997) и «Турецко-татарский словарь» (Казань–Москва, 1998), составленные совместными усилиями татарских и турецких учёных. В них

сосредоточен тот объём богатого материала, который отражает общность наших исторических корней и отвечает современному уровню развития сотрудничества между Татарстаном и Турцией в разных направлениях социально-экономических, культурных и др. отношений.

Вместе с тем всё более широкое сотрудничество Республики Татарстан в разных сферах с другими странами выдвигает новые требования и к процессу общения. В этой ситуации возникает потребность в создании больших двуязычных и многоязычных словарей татарского языка с активным привлечением иностранных языков. В условиях глобализации и стремительного развития международных связей как на уровне государств, так и отдельных регионов России увеличивается обмен специалистами в самых разных областях жизни, расширяется участие отечественных учёных, представителей бизнеса, культуры, спорта в международных конгрессах и симпозиумах, политических и экономических мероприятиях, спортивных соревнованиях, открываются новые широкие перспективы сотрудничества с зарубежными фирмами. В большинстве случаев основным средством коммуникации при этом выступает английский язык. Согласно оценке учёных, сегодня до полутора миллиарда человек во всём мире в целях общения и обмена информацией пользуются именно этим языком. Глобальные процессы в экономике, политике, стремительное развитие высоких технологий, активная, а в определённой степени даже агрессивная экспансия Интернета — всё это значительно расширяет границы распространения английского языка, выводя его далеко за пределы Великобритании, США, Канады, Австралии и других стран, традиционно считающихся англоязычными. Английский язык постепенно превращается в глобальный язык общения. В условиях такой перспективы владение английским языком становится не только престижным, но и практически необходимым атрибутом современного человека, способным существенно повлиять на успех его профессиональной деятельности. С учётом этих тенденций в международной лексикографической практике стало уделяться больше внимания созданию словарей на основе национального (татарского) и иностранного (английского) языков. Вместе с другими мерами такой подход даёт возможность носителям разных культур органично влиться в лингвистические процессы общемирового масштаба и сохранить при этом лингвоэтническую идентичность. Более того, межъязыковые контакты такого характера способны положительно повлиять не только на обогащение и развитие национальной языковой системы, но и на качество и эффективность

межкультурной коммуникации носителей данных языков.

Наряду с этим сегодня всё больше ощущается необходимость перевода произведений татарских писателей на английский и другие широко распространённые языки мира, с тем чтобы сделать классическую и современную татарскую литературу доступной читателю в мировом масштабе. Лексикографическая практика в этой деятельности составляет одно из ключевых звеньев. Поэтому актуальность создания двуязычных словарей татарского и английского языков сегодня как никогда возрастает.

В настоящее время существуют школьные, вузовские двуязычные и трёхъязычные словари небольшого объёма, такие как «Татарско-немецкий словарь» (Казань, 1989), «Англо-русско-татарский словарь физических терминов» (Казань, 1996), «Англо-татарско-русский словарь общестроительной лексики» (Казань, 1996), «Немецко-татарско-русский словарь общестроительной лексики» (Казань, 1996), «Учебный англо-татарско-русский словарь-минимум» (Казань, 1999); «Термины информатики и информационных технологий: Англо-татарско-русский толковый словарь» (Казань, 2006) и др. Имеются также двуязычные словари с английским языком, изданные в различных тюркских республиках и за рубежом (Tatar-English/English-Tatar Dictionary, 1994, 200 p.). Наиболее полными являются турецко-английские и англо-турецкие словари.

В контексте татарско-русского двуязычия создание таких словарей учебного типа без посредничества русского языка вызвало бы у большинства пользователей определённые трудности, ибо изучение английского языка в основном происходит через русский язык. Хотя, следует заметить, в последнее десятилетие развивается и направление, ставящее целью обучение иностранному языку на базе родного, татарского, языка. Двуязычные словари, созданные на основе трёхъязычных, являются более полными и точными. Поэтому в качестве первого шага на пути создания более объёмных татарско-английского и англо-татарского словарей предлагается данный «Татарско-русско-английский школьный словарь». Авторами-составителями словаря являются кандидат филологических наук С.Ф. Гарифуллин, в прошлом научный сотрудник Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Татарстана, и А. А. Тимерханов, доктор филологических наук, заведующий отделом лексикографии того же института.

Словарь составлен на основе словника хорошо известного читателю «Татарско-русского учебного словаря» (Москва, 1993, 416 с.) с сохранением его основных лексикографических принципов. Цель словаря – дать правильный и наиболее

точный перевод татарских слов на русский и английский языки. В него вошло около 12 тысяч слов и словосочетаний, в том числе ок. 1000 актуальных фразеологических единиц с их точными эквивалентами, а при отсутствии таковых – описательными вариантами на русском и английском языках. По мере возможности в словаре также учтены те изменения и новообразования, которые характерны для современного этапа развития татарского языка, что в определённой степени вызвало необходимость обновления существующего татарского словника.

За основную форму подачи татарского глагола принят инфинитив на *-ырга/-ергә,* который по своим функционально-семантическим показателям соответствует неопределённой форме глагола русского языка. Английские глаголы во многих случаях указаны с послелогами, употребление которых наиболее характерно в данном значении глагола.

В словаре также учтены случаи употребления слов одной части речи в функции другой. Ряд слов, характерных для американского варианта английского языка, а также стилистически окрашенные слова сопровождаются соответствующими пометами.

В конце словаря даётся приложение на татарском языке с кратким очерком грамматики английского языка. Этот материал справочного характера, надеемся, поможет понять и усвоить основные правила грамматики и облегчит процесс изучения иностранного языка на базе родного.

Словарь адресован широкому кругу лиц: всем тем, кто стремится расширить свой словарный запас и совершенствовать знания по татарскому и русскому языкам, а также овладеть английским языком, претендующим на статус глобального средства общения. Данный труд может служить практическим пособием для учителей школ, студентов, аспирантов и преподавателей высших учебных заведений, всех изучающих английский язык на базе родного (татарского, русского) языка или в силу профессиональной деятельности пользующихся иностранным языком. Словарь также будет полезен в переводческой деятельности и работе средств массовой информации.

Авторы с благодарностью примут замечания и отзывы по содержанию словаря. Их можно отправить по адресу: Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова Академии наук Республики Татарстана, отдел лексикографии, 420111, г. Казань, ул. Лобачевского, 2/31. Адрес электронной почты: iyali.anrt@mail.ru

*А. А. Тимерханов*

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ

1. Сүзлекнең татарча өлешендәге барлык баш сүзләр алфавит тәртибендә ярымкалын юл хәрефләре белән урнаштырылды.

2. Сүзлектә баш сүзләр (дефис аша языла торган кушма сүзләрне дә кертеп) үзләренә караган материал белән бергә сүзлек мәкаләсен тәшкил итә. Сүзнең берничә мәгънәсе булган очракта, ул мәгънәләр җәяле гарәп саннары белән аерылды. Иллюстратив материал сүзнең күрсәтелгән мәгънәсенә туры китереп бирелде.

Шакмак (□) билгесеннән соң беренче сүз принцибы белән компонентлары аерым язылган кушма һәм тезмә сүзләр, шулай ук компонентлары тотрыклы бәйләнгән сүзтезмәләр, аларның тәрҗемәләре китерелде.

Составында баш сүз беренче булып килгән аерым тотрыклы тезмәләр һәм идиомалар сүзлек мәкаләсе ахырында ромб (◊) билгесеннән соң күрсәтелде. Мәсәлән:

